**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.05.2017 Балык Бистәсе штп. № 100пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “2017-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен куллану һәм куллануга каршы көрәш” муниципаль программасын раслау турында” 2017 елның 6 апрелендәге 67пи номерлы карары белән расланган “2017-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен куллану һәм куллануга каршы көрәш” муниципаль программасының программа чаралары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең №2128-р "2020 елга кадәр чорга Россия Федерациясе халкы арасында алкогольле продукциядән чамасыз файдалану масштабларын киметү һәм алкоголизмны профилактикалау буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру Концепциясе турында" 2009 елның 30 декабрендәге боерыгы,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 16.10.2013 ел, № 764 карары белщн расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 16 мартындагы 150 номерлы карары редакциясендә), "2017-2020 елларга Татарстан Республикасында алкоголь продукциясеннән чамасыз файдалану масштабларын киметү һәм алкоголизмны профилактикалау" дәүләт программасының "2014 елга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору" ярдәмче программасы , Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы белән, Татарстан Республикасында алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендәге ситуацияне тикшереп тору Советының 2017 елның 25 апрелендәге ВШ-12-107 номерлы утырышы беркетмәсе нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “2017-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен куллану һәм куллануга каршы көрәш” муниципаль программасын раслау турында” 2017 елның 6 апрелендәге 67пи номерлы карары белән расланган “2017-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә

алкоголь продукциясен куллану һәм куллануга каршы көрәш” муниципаль программасының программа чаралары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) түбәндәге эчтәлекле 1.9 пункт өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.9 | Пенсия яшендәге кешеләр арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән мәдәни-ял чаралары оештыру | 2017-2020 еллар (ел дәвамында) | Балык Бистәсе муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) советы (килешү буенча) | - | - | - | - » |

1.2)дополнить пунктами 2.30-2.31 следующего содержания:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2.30 | Район халкы арасында алкоголизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча " түгәрәк өстәл" утырышларын оештыру | 2017-2020 еллар (ел дәвамында) | МР башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге, «Балык Бистәсе РҮХ» ДАСУ (килешү буенча) | - | - | - | - |
| 2.31 | Законсыз алкогольле продукция сату факты буенча кайнар линия телефоны хезмәтенең эшен оештыру | 2017-2020 еллар (ел дәвамында) | МР башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге, Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге (килешү буенча) | - | - | - | - |
| 2.32 | Эш урыны буенча яки яшәү урыны буенча алкогольле продукциядән чамадан тыш файдаланучы гражданнар белән эшләү өчен предприятиеләр һәм авыл җирлекләре (иптәшләрчә суд формасында) вәкилләре арасыннан Иҗтимагый совет төзү | II квартал 2017 года | МР башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге | - | - | - | - » |

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин